КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 420

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау» 2014 ел, 7 июль, 455 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау» 2014 ел, 7 июль, 455 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 июнь, 418 нче; 2017 ел, 19 октябрь, 796 нчы; 2020 ел, 26 июнь, 534 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2014 – 2022 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1.1 пунктта «2014 – 2022 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Бу Тәртипнең 1.2 пунктында каралган максатларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы.

Тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында, шулай ук тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын формалаштырганда, субсидияләр турында мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) урнаштырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 1.3[1] пункт өстәргә:

«1.3[1]. Субсидия бирү өчен субсидия алучыны сайлап алу (алга таба – сайлап алу) конкурс ысулы белән гамәлгә ашырыла, ул, субсидия бирелә торган нәтиҗәләргә (алга таба – субсидия бирү нәтиҗәсе) ирешүнең иң яхшы шартларыннан чыгып, субсидия алучыны билгеләгәндә үткәрелә.

Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән кимрәк була алмаган сайлап алуны үткәрү сроклары (сайлап алуда катнашу өчен иҗтимагый оешмалар тарафыннан җибәрелгән заявкаларны (алга таба – заявка) бирә (кабул итә) башлау (бирүне, кабул итүне тәмамлау) датасы һәм вакыты);

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 1.2 пунктында каралган субсидия бирү максатлары, шулай ук бу Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән иҗтимагый оешмаларга карата таләпләр һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен иҗтимагый оешмалар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 2.3 – 2.10 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

иҗтимагый оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – шартнамә) имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене шартнамә төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруның сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган датасы.

Иҗтимагый оешма сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү бердәм порталда урнаштырылган көннән Министрлыкка бу Тәртипнең нигезләмәләренә аңлатма бирү турында язмача сорату җибәрергә хокуклы. Әгәр әлеге сорату Министрлыкка заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча кергән булса, Министрлык әлеге сорату кергән датадан биш эш көне эчендә бу Тәртипнең нигезләмәләренә аңлатмаларны язмача яки электрон документ рәвешендә җибәрә.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Иҗтимагый оешмалар сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 числосына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

иҗтимагый оешмаларның салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

иҗтимагый оешмаларның субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмаска тиеш;

иҗтимагый оешмалар үзгәртеп оештыру (иҗтимагый оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска тиеш, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, иҗтимагый оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булырга тиеш;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында коллегиаль башкарма органның дисквалификацияләнгән җитәкчесе, әгъзалары, бер генә кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки иҗтимагый оешманың баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмаска тиеш;

иҗтимагый оешмалар чит ил юридик затлары, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә һәм (яки) финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачу һәм бирү каралмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аларның теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан арткан Россия юридик затлары булмаска тиеш;

иҗтимагый оешмалар бу Тәртипнең 1.2 пунктында каралган максатларга Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Сайлап алуда катнашу өчен иҗтимагый оешмалар Министрлыкка аның тарафыннан расланган форма буенча заявка бирә.

Иҗтимагый оешмалар тарафыннан бирелә торган заявкаларда шул исәптән иҗтимагый оешма турындагы, иҗтимагый оешма тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны, иҗтимагый оешма турында сайлап алуга бәйле башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык булырга тиеш.

Заявкага түбәндәге документлар теркәлә:

проектның максатлары һәм бурычлары тасвирламасын, төп чаралар күрсәткечен, шул исәптән 100 индивидуаль һәм төркем белән социаль-психологик консультацияләр биреләчәк наркотиклар куллануга бәйле гражданнар санын, көтелә торган нәтиҗәләрне, шулай ук проектны тормышка ашыруның календарь планын, акча тоту юнәлешләре һәм күләмнәре (финанслау күләмнәре) каралган проект бюджетын, наркотиклар куллануны туктаткан затларның хезмәт социализациясен оештыру яки популярлаштыру өлкәсендә чаралар үткәрү буенча методик тәкъдимнамәләр эшләү турында, психологик белеме булган йә «Психолог» белгечлеге буенча яңадан әзерлек үткән яки квалификациясен күтәргән һәм наркотиклар куллануга бәйле кешеләргә даими социаль-психологик булышлык күрсәтеп тору өлкәсендә кимендә өч ел эш тәҗрибәсе булган квалификацияле белгечләр проектын гамәлгә ашыруда катнашу турындагы мәгълүматны үз эченә алган проект. Шул ук вакытта проектны тормышка ашыру срогы 10 айдан кимрәк һәм 12 айдан артыграк була алмый, ә аны тормышка ашыруны тәмамлау срогы субсидия биргән елдан соң килә торган елның 31 октябреннән дә соңрак була алмый;

оешманың наркотиклар куллануга бәйле гражданнарны эшкә урнаштыру тәҗрибәсе турында булган, Татарстан Республикасы территориясендә наркотиклар куллануны туктаткан затларны хезмәт социализациясе буенча кимендә өч ел эшчәнлек алып баруын раслый торган аналитик мәгълүмат;

иҗтимагый оешма уставының күчермәсе, шулай ук аңа үзгәрешләр кертү турындагы документларның күчермәсе;

оешманы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазенең күчермәсе;

иҗтимагый оешма әгъзаларының саны турында аның җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

иҗтимагый оешманың штат расписаниесе күчермәсе;

иҗтимагый оешманың чыгымнар сметасы күчермәсе;

үткән финанс елына бухгалтерлык балансы күчермәсе;

иҗтимагый оешма тарафыннан «Иҗтимагый берләшмәләр турында» 1995 елның 19 маендагы 82-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үз эшчәнлеген дәвам итү турындагы мәгълүматны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә бирүне раслый торган документларның күчермәләре;

заявка бирелгән көнгә кадәр өч айдан да иртәрәк булмаган вакытта Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтәнең күчермәсе;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазе;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән башка бурычлар булмавы турында иҗтимагый оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган, мөһер белән расланган белешмә кәгазе;

иҗтимагый оешманың үзгәртеп оештыру (иҗтимагый оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын раслый торган белешмә кәгазе;

иҗтимагый оешмаларның чит ил юридик затлары, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә һәм (яки) финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачу һәм бирү каралмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аларның теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан арткан Россия юридик затлары булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

иҗтимагый оешманың бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган, иҗтимагый оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе.

Иҗтимагый оешма тарафыннан бу пунктның җиденче, уникенче, унөченче, ундүртенче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Иҗтимагый оешма заявкаларны бирү срогы чыкканга кадәр үз заявкасына үзгәреш кертергә яки кире алырга хокуклы. Әгәр заявкага үзгәреш кертү яки Министрлык тарафыннан хәбәрнамә заявкалар бирү срогы тәмамланганга кадәр алынган булса, заявкага үзгәреш кертү яки аны кире алу турында хәбәрнамә гамәлдә була.

Иҗтимагый оешма иң күбе бер заявка бирергә мөмкин.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Заявкалар кабул итү срогы башланганга кадәр яки заявкалар (шул исәптән аларны почта аша) кабул итү срогы тәмамланганнан соң Министрлыкка кергән заявка

теркәлми һәм кире кайтарылмый, бу турыда Министрлык тарафыннан иҗтимагый оешмага заявка кергән көннән 10 эш көне эчендә заявкада күрсәтелгән адрес буенча язмача хәбәр итә.»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Заявканы карап тикшерү иҗтимагый оешмаларның наркотиклар куллануны туктаткан затларны хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыру өчен субсидияләр бирү турындагы заявкаларын карап тикшерү буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) тарафыннан гамәлгә ашырыла. Эшче төркем составы Министрлык хезмәткәрләреннән төзелә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

Эшче төркем заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә әлеге теркәлгән заявкаларны керү чираты буенча һәм заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү стадиясендә заявкаларны кабул итүдән баш тарту өчен бу Тәртипнең 2.6 пунктындагы икенче – алтынчы абзацларында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерүгә кергән датадан һәм вакыттан чыгып карый, заявкага сайлап алуда катнашырга рөхсәт итү турында яки заявканы кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә. Кабул ителгән карар заявкаларны карап тикшерү тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә эшче төркем утырышының беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа эшче төркемнең һәр әгъзасы тарафыннан имза куела.»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү стадиясендә заявканы кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

иҗтимагый оешманың бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

иҗтимагый оешма тарафыннан тапшырылган заявкаларның һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

иҗтимагый оешма тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән иҗтимагый оешманың урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

иҗтимагый оешма тарафыннан заявканың аларны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

иҗтимагый оешманың бу Тәртипнең 1.4 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве.»;

2.7 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Сайлап алуда катнашырга рөхсәт итү турында карар кабул ителгән заявкаларны бу Тәртипнең 2.9 пунктында каралган критерийлар нигезендә карап тикшерү һәм бәяләү Наркотиклар куллануны туктаткан затларны хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларның субсидияләр бирүгә заявкаларын карап тикшерү һәм сайлап алуда җиңүчене билгеләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Комиссия Министрлык хезмәткәрләреннән төзелә. Комиссия составына Министрлык каршындагы иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук килешү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы бүтән башкарма

органнары һәм федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләре кертелә.»;

2.10 пунктның өченче абзацын төшереп калдырырга;

2.11 – 2.14 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11. Заявкалар рейтингы һәм сайлап алуда җиңүчене билгеләү заявкаларны карап тикшергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия әгъзалары тарафыннан имза куела һәм ул Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + ... + З_n,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, ..., $З_n$ – бу Тәртипнең 2.14 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча Министрлык тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган оештыручы-җитештерүчеләрнең бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар суммасы.

Субсидия заявкалар рейтингында беренче урын алган иҗтимагый оешмага бу Тәртипнең 1.2 пунктында каралган максатлар өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре күләменә туры килә торган, Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаган күләмдә бирелә.

Комиссия утырышының беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкаларны бәяләү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән иҗтимагый оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган иҗтимагый оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

заявкаларны бәяләү эзлеклелеге, заявкаларны бәяләүнең күздә тотылган һәр критерие буенча заявкаларга бирелгән күрсәткечләр, заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә мондый заявкаларга тәртип саннарын бирү турында кабул ителгән карар;

шартнамә төзелә торган иҗтимагый оешманың (сайлап алуда җиңүченең) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

Сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасын, вакытын һәм урынын;

заявкаларны бәяләү датасын, вакытын һәм урынын;

заявкалары карап тикшерелгән иҗтимагый оешмалар турындагы мәгълүматны;

заявкаларын кабул итүдән баш тартылган иҗтимагый оешмалар турындагы мәгълүматны (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алу үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

заявкаларны бәяләү эзлеклелеге, заявкаларны тәкъдим итүләрне бәяләүнең күздә тотылган һәр критерие буенча заявкаларга бирелгән күрсәткечләр, заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре нигезендә заявкаларга тәртип саннарын бирү турында кабул ителгән карарны;

шартнамә төзелә торган иҗтимагый оешманың исемен һәм аңа бирелә торган субсидия күләмен.

2.12. Министрлыкның иҗтимагый оешмага субсидия бирү турындагы карары Комиссия тарафыннан бу Тәртипнең 2.11 пунктында күрсәтелгән беркетмәгә имза куелган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә кабул ителә.

2.13. Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган унөч көн эчендә иҗтимагый оешма (сайлап алуда җиңүче) белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә шартнамә төзи.

Шартнамә төзү өчен Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә шартнамә проектын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә иҗтимагый оешманың заявкасында күрсәтелгән электрон почта адресына җибәрә.

Иҗтимагый оешма ике нөсхәдә, кәгазьдә булган шартнамәгә имза куя һәм аларны шартнамә проекты электрон почта адресына килгән көннән өч эш көне тәмамланганга кадәр Министрлыкка тапшыра.

Иҗтимагый оешмадан имзаланган шартнамә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Министрлык шартнамәгә имза куя һәм аның бер нөсхәсен иҗтимагый оешмага җибәрә.

Әгәр шартнамә проекты иҗтимагый оешманың электрон почтасы адресына килгән көннән биш көн эчендә иҗтимагый оешма тарафыннан Министрлыкка ике нөсхәдә имзаланган шартнамә тапшырылмаса, иҗтимагый оешмага субсидия бирү турындагы карар гамәлдән чыгарылган дип, ә иҗтимагый оешма шартнамә төзүдән баш тарткан дип санала.

Иҗтимагый оешма тарафыннан Министрлыкка үзенең имзасы куелган, бу пунктның дүртенче абзацында билгеләнгән шартнамә тапшыру срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ун көн эчендә Министрлык иҗтимагый оешмага аңа субсидия бирү турындагы карар гамәлдән чыгарылу турында язмача хәбәр итә.

Килешүдә шул исәптән түбәндәгеләр карала:

субсидиянең максатчан билгеләнеше һәм аның күләме;

субсидияне күчерүнең тәртибе һәм сроклары (кабатланып тору вакыты);

субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка киметелгән очракта, шартнамәнең яңа шартларын килештерү турында (яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында) субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт;

шартнамәгә үзгәрешләр кертү (шул исәптән бюджет акчасын алучы буларак баш эш итүчегә субсидия бирү өчен элегрәк җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта) нигезләре һәм тәртибе;

шартнамә шартларын бозган өчен җаваплылык;

иҗтимагый оешма тарафыннан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары һәм әлеге хисапны бирү формасы;

өстәмә хисап бирү сроклары һәм формасы (кирәк булганда);

иҗтимагый оешма тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган, субсидия күчерелә торган исәп-хисап счетының реквизитлары;

субсидия акчасыннан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, субсидияне кире кайтару тәртибе һәм сроклары, иҗтимагый оешма тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару очраклары;

иҗтимагый оешманың кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгы, иҗтимагый оешманың, шулай ук иҗтимагый оешма белән төзелгән шартнамәләр нигезендә субсидия акчасын алучы затларның Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан аларга карата субсидия бирү һәм аннан файдалану максатлары, шартлары, тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

иҗтимагый оешма, шулай ук иҗтимагый оешма белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуга тыю;

иҗтимагый оешма тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына субсидия күчерүгә ризалык;

иҗтимагый оешманың, шулай ук иҗтимагый оешма белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, аларның устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнаша торган хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук аларның устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнаша торган коммерциягә караган оешмалардан тыш) Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан аларга карата субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы.

Шартнамәгә үзгәрешләр кертү Якларның килешүе буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең (шартнамәнең) бертип формасына кушымтада китерелгән форма буенча шартнамәгә өстәмә килешү төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Шартнамәне өзү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең (шартнамәнең) бертип формасына кушымтада китерелгән форма буенча шартнамәгә өстәмә килешү төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

2.14. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре:

проектны тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү;

проектны тормышка ашыруны тәэмин итү өчен кирәкле товарлар, хезмәт күрсәтүләр, эшләр башкару, бүлмә, җиһаз һәм җайланма арендалау өчен түләү;

проектта катнашучылар өчен наркотиклар куллануга бәйле булган затларны ресоциализацияләүгә юнәлдерелгән чаралар һәм тематик очрашулар үткәрү.

Иҗтимагый оешма, шулай ук иҗтимагый оешма белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.»;

2.15 пунктта:

«кредит оешмаларында» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирүнең шарты – иҗтимагый оешманың, шулай ук иҗтимагый оешма белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, аларның устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнаша торган хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук аларның устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнаша торган коммерциягә караган оешмалардан тыш) Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан аларга карата субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Субсидия бирүнең нәтиҗәләре:

проектны тормышка ашыру срогы тәмамланган көнгә, әмма субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 31 октябреннән дә соңга калмыйча, наркотиклар куллануга бәйле гражданнарга кимендә 100 индивидуаль һәм төркем белән социаль-психологик консультацияләр бирү;

проект тәмамланган вакытка, әмма субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 31 октябреннән дә соңга калмыйча, наркотиклар куллануны туктаткан затларның хезмәт социализациясен оештыру яки популярлаштыру өлкәсендә чаралар үткәрү буенча кимендә бер методик тәкъдимнамә эшләү.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Иҗтимагый оешма Министрлыкка шартнамә төзелгән датадан субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 30 июненнән – 15 июленә кадәрге чор өчен һәм шартнамә төзелгән датадан субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 30 ноябреннән – 1 декабренә кадәрге чор өчен субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең (шартнамәнең) бертип формасына кушымталарда китерелгән формалар буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап кертә;»;

4.1 пунктта «тикшерү» сүзен «мәҗбүри тикшерү» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Иҗтимагый оешма тарафыннан субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган очракта, шулай ук бу Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләр күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, иҗтимагый оешма субсидияне Татарстан Республикасы бюджеты кеременә тулы күләмдә кире кайтарырга тиеш:»;

әлеге Тәртипкә кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин